РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«23» июнь 2020г. г. Альметьевск №381

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2015 елның 10 декабрендәге «Әлмәт муниципаль районының муниципаль хезмәткәренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә бирелә торган бүләкләү күләме һәм тәртибе турында»гы 36 нчы номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы нигезендә, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 30 мартындагы 197 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, бюджет акчаларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге принцибын үтәүне тәэмин итү максатларында

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2015 елның 10 декабрендәге «Әлмәт муниципаль районының муниципаль хезмәткәренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә бирелә торган бүләкләү күләме һәм тәртибе турында»гы 36 нчы номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Әлмәт муниципаль районының муниципаль хезмәткәренә тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә бирелә торган бүләкләү күләме һәм тәртибе» турындагы карарына кушымтада:

1.1.1. 2 пунктта «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт стажы 15 ел булганда» сүзләрен «тиешле елда тиешле еллар эшләгән өчен пенсия билгеләү өчен дәвамлылыгы түбәндәгечә исәпләнә торган муниципаль хезмәт стажы булганда» сүзләренә алмаштырырга:

- 2020 елда 17 ел,
- 2021 елда 17 ел 6 ай,
- 2022 елда 18 ел,
- 2023 елда 18 ел 6 ай,
- 2024 елда 19 ел,
- 2025 елда 19 ел 6 ай,
- 2026 һәм аннан соңгы еллар 20 ел»;

1.1.2. 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Заказ № 1146-100

«4. Пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә бирелә торган бүләкләү күләмен билгеләгәндә исәпкә алына торган айлык акча составына түбәндәгеләр керә:

вазыйфаи оклад;

сыйныф чины өчен вазыйфаи окладка айлык естәмә түләү;

муниципаль хезмәтнең махсус шартлары өчен вазыйфаи окладка айлык өстәмә.».

2. Башкарма комитетның хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталы»нда (PRAVO.TARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, җирле салымнар һәм җыемнар буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Мусин Р.Ф.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов